**ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл жирлегенең Тегермәнче торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2 28 ноябрь 2025

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Тегермәнче торак пунктында халык жыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге Тегермәнче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Тегермәнче торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү).

2) Тегермәнче торак пунктының башка территорияларын төзекләндерү (хуҗасыз участокларны койма белән әйләндереп алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

3) Тегермәнче торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Речная һәм Новая урамнарында юлларны ремонтлау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иркеняш авыл җирлеге мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы И.З. Камалов